| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>ОЛУЯЗСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ<br>422127, РТ, Кукморский район, с.Олуяз, ул. Новая, д. 11<br>Эл.почта: Olu.Kuk@tatar.ru<br>тел./факс: 8 (84364) 39-5-83 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ОЛЫЯЗ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>422127, РТ, Кукмара районы, Олыяз авылы, Яңа урам, йорт 11<br>Эл.почта: Olu.Kuk@tatar.ru<br>тел./факс: 8 (84364) 39-5-83 |
|---|---|

# КАРАР

3 июль 2023 ел № 16

«Кукмара муниципаль районы Олуяз авыл җирлегенең Түбән Казаклар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»25.11.2022 ел, №1 Түбән Казаклар авылы гражданнары җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районы Олуяз авыл җирлегенең Түбән Казаклар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Олуяз авыл җирлеге Уставына, Олуяз авыл җирлеге Советы

Карар кабул итте:

1.«Кукмара муниципаль районы Олуяз авыл җирлеге Түбән Казаклар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»25.11.2022 ел, №1 Түбән Казаклар авылы гражданнары җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2023 елның 14 июлендә 15 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә. Түбән Казаклар авылы, М.Җәлил урамы, 18 адресы буенча урнашкан спорт мәйданчыгында гражданнар җыенын уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Кукмара муниципаль районы Олуяз авыл җирлегенең Түбән Казаклар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында " 25.11.2022 ел, №1 Түбән Казаклар авылы гражданнары җыены карарына гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча кертүгә ризамы?:
2 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
5 нче линияне монтажлау, энергияне саклаучы лампалар, яктырткычлар, Түбән Казаклар авылы өчен махсус җиһазлар сатып алу; смета документациясен төзү?

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р. Ф. Маликов